ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__406____ от «_02_»____07____2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2012 елның 20 нче июнендә кабул ителгән
1090 нчы санлы карарына үзгәрешләр
кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ санлы Федераль законы нигезендә,норматив – хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында карарларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 20 нче июнендә кабул ителгән 1090 нчы санлы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү регламентын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.2. пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Җирле үзидарә органы тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү) – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә, шулай ук күрсәтелгән Федераль законда каралган җирле үзидарә органнарының хокуклары чикләрендә билгеләнгән җирле әһәмияттә булмаган мәсьәләләрне хәл итү буенча, җирле үзидарә органнарының башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу хокуклары (күрсәтелгән Федераль законның 19 маддәсе нигезендә аларга тапшырылмаган), әгәр дә бу катнашу федераль законнар, җирле үзидарә органнарының башка муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән, мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән алар компетенциясеннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вәкаләтләре чикләрендә мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов